СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел, « 14 » март** **№ 227**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары законнарына һәм норматив хокукый актларына үзгәреш кертү мониторингы үткәрү турында Нигезләмә раслау турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (бастырылган) законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәреш кертү мониторингы үткәрү буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Арча район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары законнарына һәм норматив хокукый актларына үзгәреш кертү мониторингы үткәрү турында бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

үз нормаларын чыгару эшчәнлегендә әлеге Карарның 1 нче пунктында расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

әлеге Нигезләмә үтәлеше өчен җаваплы кешеләрне билгеләргә;

җаваплы итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Муниципаль норматив хокукый актлар законнарга, муниципаль берәмлекләрнең уставларына туры килүен системалы рәвештә тикшереп торуны тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына кергән җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына мониторинг үткәрүне күздә тотучы муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башлыгы урынбасары һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

6. Әлеге карар аны рәсми рәвештә бастырганнан соң ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы башлыгы И.Г.Нуриев

Расланды
Татарстан Республикасы
Арча район Советының
201__ елның «____» _________
___ номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары законнарына һәм норматив хокукый актларына үзгәреш кертү мониторингы үткәрү турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары законнарына һәм норматив хокукый актларына үзгәреш кертү мониторингы (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару), аларга үзгәрешләр кертү яки үз көчләрен югалткан дип тану (кире кагу) максатында мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлек алып баруны күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргән вакытта Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр буенча бүлеге һәм муниципаль берәмлекнең башка җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы кешеләр билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары:

федераль һәм республика законнарына туры китерү максатында муниципаль актларны кабул итү, аларга үзгәреш кертү яки үз көчләрен югалткан дип тану ихтыяҗлары барлыгын ачыклау;

муниципаль актларда коллизияләр, каршылыклар, бушлыкларны, хокукый җайга салуда кабатлауларны бетерү;

җирле үзидарә органнарының хокукый-норматив базасын системага китерүне тәэмин итү;

муниципаль актларда ришвәтчелек факторларын ачыклау;

гамәлдә файдаланылмаган (әһәмиятен югалткан) яки кулланылмый торган муниципаль актларны яки аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген киметә торган факторларны ачыклау;

җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан муниципаль актлар үтәлешен тикшерүгә ярдәм күрсәтү;

нормалар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг үз эченә:

федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка закон актларын;

Россия Федерациясе Президенты указларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, федераль башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актларны;

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставын, муниципаль актларны җыюны, гомумиләштерүне, анализлауны һәм бәяләүне ала.

7. Мониторинг үткәрү өчен нигез булып тора:

федераль һәм республика актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салуның аерым өлкәсендә муниципаль актлар куллануны анализлау;

прокуратура органнарыннан кергән мәгълүмат;

муниципаль актларда булган кимчелекләр яки аларны камилләштерү кирәклеге турында массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүмат;

муниципаль актларның камил булмавы турында, шул исәптән:

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга карата Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы уздырган хокукый экспертиза нәтиҗәләрен;

вәкаләтле затлар тарафыннан тиешле тәртиптә үткәрелгән муниципаль актларның ришвәтчелеккә каршы экспертизасы нәтиҗәләрен;

конференция, семинарлар, ачык тыңлаулар, җәмәгать тикшерүләре һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан уздырыла торган башка чараларның йомгаклау документларын үз эченә алган гражданнардан, юридик затлардан, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмалардан, шәхси эшмәкәрләрдән, дәүләт хакимияте органнарыннан, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан кергән мөрәҗәгатьләр.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләренә караган сораулар буенча әлеге Нигезләмәнең 4 нче пунктында күрсәтелгән җавааплы кешеләр белән берлектә мониторинг уздыра.

Мониторинг үткәрү максатында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат сорап алынырга, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясе субъектларының башка муниципаль берәмлекләре тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш төрләре кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг:

әлеге Нигезләмәнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән актларны;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актларын (суд практикасын);

прокурор актларын анализлау аша башкарыла.

10. Мониторинг үткәрү, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча башкарылган нормалар чыгару нәтиҗәләрен билгеләү максатында җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карары нигезендә алып барыла торган муниципаль норматив хокукый актлар кулланыла.

11. Мониторинг үткәрү барышын җиңелләштерү өчен мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары (аларның операторлары белән контракт, килешү төзү мөмкинлеге булган очракта) кулланыла. Алар:

«Консультант Плюс» мәгълүмат системасында тикшерүгә куелган законнар һәм башка норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында;

«Консультант Плюс» мәгълүмат системасында тиешле хокук өлкәсе буенча яңалыклар кертелү турында;

«Кодекс» мәгълүмат компаниясының «Төбәк законнары аналитигы» («Аналитик регионального законодательства») автоматлаштырылган мәгълүмат системасына муниципаль актларның законнарга туры килмәү очраклары турында мәгълүмат керүне тәэмин итә.

Мониторинг үткәрү барышын җиңеләйтү максатында башка мәгълүмат системалары сервислары кулланылырга мөмкин.

12. Муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару), аларга үзгәрешләр кертү яки үз көчләрен югалткан дип тану (кире кагу) максатында мониторинг үткәргән вакытта әлеге Нигезләмәнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән анализ белән берләттән муниципаль актларны куллану гамәле турындагы мәгълүмат түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) кирәклеген билгели торган югарырак юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булу;

муниципаль акт кабул иткәндә җирле үзидарә органы вәкаләтләре чигендә эш итү;

муниципаль актта ришвәтчелек факторлары булу;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда тулылык;

хокук нормалары коллизиясе;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

кулланган вакытта муниципаль акт нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) булу;

норматив хокукый актларны куллану практикасы булу;

норматив хокукый актларны куллануның бертөрле практикасы булмау;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар булу (саны) һәм аларның эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында законлы көченә кергән суд актлары һәм аларны кабул итү нигезләре булу (саны).

13. Мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль актларга үзгәреш кертүне таләп итүче федераль һәм республика законнарына кертелгән үзгәрешләр ачыкланса, җирле үзидарә органнары тарафыннан:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актларның үз көчен югалтуы турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында муниципаль акт проектлары эшләнә;

муниципаль актларны югарырак юридик көчкә ия булган актларга туры

китерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14. Федераль һәм республика законнары актларына кертелгән үзгәрешләр муниципаль актларга да үзгәреш кертүне таләп иткән очракта мониторинг федераль яки республика акты чыкканнан соң 30 көн эчендә башкарыла.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып граждыннардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, дәүләт хакимияте органнарыннан, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан кергән мөрәҗәгать, шулай ук прокуратура мәгълүматы торган очракта, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законда билгеләнгән вакыт аралыгында карала торган прокурор актларыннан тыш, мониторинг мондый мөрәҗәгать һәм мәгълүмат кергән көннән соң 30 көн эчендә үткәрелә. Мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт проектын эшләү һәм муниципаль актны кабул итү федераль һәм (яки) республика законнары актына үзгәреш керткәннән соң, әлеге Нигезләмәнең 14 нче пунктының өченче кызыл юлында күрсәтелгән очрактан тыш, ике айдан да соңга калмыйча башкарыла.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы кешеләр җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисаптан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында;

мониторинг үткәргән кешеләр турында;

мониторинг үткәрү вакыты турында;

хокукый җайга салуның кыскача бәяләмәсе, мониторинг үткәрү сәбәбе.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актлар кабул итү, кире кагу зарурлыгы буенча тәкъдимнәр;

хокукый мөнәсәбәтләрнең аерым өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча яңа кабул ителгән муниципаль актлар законда каралган тәртиптә һәм вакыт аралыгында Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрелә.

Әлеге регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган, анда булмаган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләреннән чыгып, норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә караган хокукый җайга салуның тиешле өлкәсендә муниципаль актларны федераль һәм республика законнары белән тәңгәлләштерүне вакытында башкару өчен мониторинг үткәрү һәм хокук чыгару эшчәнлеге өчен җаваплы кешеләр шәхси (шул исәптән дисциплинар) җавап бирә.

20. Мониторинг нәтиҗәләре буенча тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җирле үзидарә органнары җитәкчеләре закон буенча җавап бирә.